# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлегенең Әлмәт авылы торак пунктында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

№1 20.11.2024

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары нигезендә 2024 елның 20 ноябрендә «I нче группа инвалидлар, ялгыз өлкән кешеләр, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан кала, Әлмәт авыл җирлегендә теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2025 елда үзара салымны 350 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:
1) Әлмәт авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту;
2) Әлмәт торак пунктының Ленин ур., Тукай ур., Яшьләр ур., Л. Рәхмәтуллин ур. буенча авыл эчендәге юлларны ремонтлау (материалларны сатып алу һәм транспортировкалау, эш өчен килешү буенча түләү) ;
3) Әлмәт торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кардан чистарту (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) ;
4) Әлмәт торак пунктында торак пункт территориясен төзекләндерү (җәйге вакытта территорияне чабу (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү); МТЗ 82.1 тракторына, триммерлар һәм генератор өчен ягулык-майлау материаллары, МТЗ 82.1тракторына, триммерларга запас частьләр сатып алу);

ӘЙЕ ЮК?».

мәсьәләсе буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 314 катнашучы кертелгән, җыенда катнашучылар саны 177кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 177 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге составына керүче Әлмәт авылында узган халык җыенын-уздырылган, нәтиҗәләрен- дөрес дип танырга.